# *Күкләр зәңгәр, Чулман зәңгәр бүген... Шифа эзләп Күктән, атлап барам*



## АНА МОНОЛОГЫ

Сине үлгән диләр, газиз балам.
Хәбәр килде. Хәбәр китерделәр...
Сине түгел... Сине генә түгел...
Чал анаңны бүген... үтерделәр...

Сиңа анда суык микән, балам?
Яу кырында, диләр жәсәденне.
Яу кырында ядрә ява, диләр...
Ядрә микән, әллә яшьләремме?

Синең жаның бәргәләнәме ул,
Минем жанмы – ядрә арасында?
Жан мәңгелек, диләр... Нигә хәсрәт
Оныттыра икән барысын да?

Сабырлыгым ничек кайтарасы –
Сынмас өчен Раббым сынавыннан?
Авыр, балам... Көтүләре авыр...
Билгесезлек – гүр газабы сыман.

Ак биләүгә биләп сабый чакта,
Имезгәндә күкрәк сөтләремне,
Ак кәфенгә төреп, соң йортыңа
Озатырмын, диеп теләдемме...

Ак биләүгә биләп озатулар
Язсын, диеп дога кылган мәлем.
Газиз балам... Жир куйнына салсам,
Жиңеләер кебек әле хәлем.

Тынычланыр жаным – синең жаның
Озаталсам Раббым каршысына;
Син әйтергә өлгерәлми калган
Шәһәдәтне пышылдасам гына...

Син эшләргә өлгерәлми калган
Күпме эшләр калды бу фанида...
Балаларың сыңар канат калды...
Каһәр төшсен сезгә, зобаныйлар!

...Төсе китте сыман дөньясының.
Хәбәр килде. Хәбәр китерделәр...
Сине генә түгел, йөрәк парәм,
Чал анаңны бүген үтерделәр...

* * *

Күкләр зәңгәр, Чулман зәңгәр бүген...
Зәмзәм суы сыман шифалы көн.
Нәкъ шул мизгел – чып-чын барлык әле,
Ә калганы – күзгә сарыр төтен.

Күкләр зәңгәр, Чулман зәңгәр бүген...
Жете төсләр тама пумаладан.
Жете якты төскә сусаган чак –
Жанны никтер сөрем томалаган...

Жете кызыл төсне сөймим хәзер,
Жете кара төстән жаным ара...
Күкләр зәңгәр, Чулман зәңгәр бүген...
Шифа эзләп Күктән, атлап барам.

## ӨЗГӘЛӘНӘ БУЛЫР СҮЗ ИЯСЕ...

Әллә сүзләр очсыз,
Әллә инде
Сүз бәһасын бозган кешеләре?
Сүзне, көчләп,
Фәхеш ясаучылар
Сүзнең Хакын
Әллә төшенәме?!

Сүзне, кармак итеп, бөгә-бөгә,
Үзгәрткәндә жәнаб асылларын...
Үзгәрәләр йөзләр,
Калеб,
Холык,
Үзгәләнә күңел фасыллары.

Сүздән киткән дөнья
Өзгәләнә...
Өзгәләнә –
Нәфес азгынлыкка.
Жанүзәктән читкә тибәрелгән
Сүзнең таруына ялгызлыкка.

Сүзнең ялчылыкка калуына
Өзгәләнә булыр Сүз Иясе.
Син бит – синең Сүзең.
Шуңа өстәп, ни диясе соң ул?
Ни диясе?..

* * *

Әллә елар, әллә көләр
Сәбәп эзлим.
Ач күз белән нидер күзлим.
Нидер күзлим...
Богауланып,
Тынып калган
Сүз мин.

Тамам, тамам, диеп
Тора яшем.
Һәр тамчыда
Дөнья гаме яши.
Саклап кара тәкәллефле йөзең –
Меңәр еллык сыкрау тулы
Сүз мин.

Сөмсез жилләр
Яңак чабып уйный.
Басып торам чатта
Түзәр-түзми.
Каһкаһәле еллар давылында,
Егылмыйча,
Исән калган Сүз мин.

Жиде чатта жиде уйны сүтәм –
Уң юл табарыма
Өмет өзмим.
Мәңгелекнең фани бишегендә –
Дөнья яралганда
Туган Сүз мин.

Хәзер генә менә
Ач күз белән
Нидер эзлим Жирдә.
Нидер эзлим...